КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

2018 ел, 27 сентябрь г.Казань № 856

Татарстан Республикасында рисска юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеген раслау турында

«Дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшерүне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче Федераль законны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында рисска юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә, Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә (күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) өлешендә), Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына 2018 елның 1 ноябренә кадәр, федераль законнар белән билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) оештырганда юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлеген һәм (яки) алар файдалана торган җитештерү объектларын рискның

билгеле бер категориясенә яисә куркынычлыкның билгеле бер классына (категориясенә) кертү критерийларын билгели торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеше күзәтчелеге инспекциясенә (күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) өлешендә), Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына (транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәре үтәлешен тикшерүдә тоту өлешендә), Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсенә, Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына 2018 елның 1 ноябренә кадәр, федераль законнар белән билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, тиешле эшчәнлек өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) (төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләрен) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртипләрен билгели торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларын яисә тиешле эшчәнлек өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) (төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләрен) оештыру һәм гамәлгә ашыруның гамәлдәге тәртипләренә үзгәрешләр кертү турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 27 сентябрь, 856 нчы карары белән расланды

Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеге

Т/с	Төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төренең исеме
1.	Төбәк дәүләт экология күзәтчелеге
2.	Махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге
3.	Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге
4.	Төбәк дәүләт торак күзәтчелеге
5.	Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлегенә лицензия тикшерүе
6.	Алкогольле продукцияне ваклап саткан өчен лицензия тикшерүе
7.	Күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге)
8.	Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге
9.	Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге
10.	Төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеге
11.	Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге)
12.	Транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәре үтәлешен тикшерүдә тоту.